# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**“13” ноябрь 2024 ел** **№10**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 13 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу һәм китерү, Сәрдәбаш авылы Җиңүнен 65 еллыгы, Маршал Жуков, Г.Тукай урамнарында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Сәрдәбаш авылында урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән 15 данә яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.»

Халык җыены йомгаклау беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 203 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 106 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 106 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Сәрдәбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу һәм китерү, Сәрдәбаш авылы Җиңүнен 65 еллыгы, Маршал Жуков, Г.Тукай урамнарында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Сәрдәбаш авылында урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән 15 данә яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Сәрдәбаш авылы, Җиңүнең 65 еллыгы урамы, 28 йорт, Г.Тукай урамы, 1А йорт адреслары буенча, Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчент Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы Шушмабаш
авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов